Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Югары-Чура авыл җирлеге Советы

КАРАР

«25» февраль, 2026 ел № 4

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары-Чура авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында» 2022 елның «17» мартында 4 номерлы Югары-Чура авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгару хакында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Югары-Чура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Югары-Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары-Чура авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында» 2022 елның «17» мартында 4 номерлы Югары-Чура авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы урынбасары Афанасьев А.Н.